гаризаны 10 көн эчендә карарга тиеш. Шул вакыттан әлеге факт буенча җинаять эшен кузгалту яки, киресенчә, кузгалтмау турында карар чыгарачаклар. Телефон иминиятләштерелгән очракта, шул карарны бер-кетеп, иминият компаниясенә мөрәҗәгать итәргә була.

## ТЕЛЕФОН САТЫП АЛУЧЫГА 5 КИҢӘШ

**1.** Телефон сатып алыр алдыннан үзегезгә кайсы модель кирәк икәнен алдан ук төгәл билгеләгез.

**2.** Аеруча интернет аша телефон алганда артык арзанга кызыкмагыз, башта товар, сайт турында фикерләрне укып чыгыгыз.

**3.** Телефонның техник характеристикасы белән танышыгыз. Куллану тәртипләрен өйрәнегез. Телефонның шәхси номерына (IMEI) игътибар итегез. Әлеге номерны *#06# кодын җыеп белергә була. Бу номерның телефон корпусындагы, товарның кабындагы һәм аккумуляторындагы номер белән тәңгәл килүе шарт.

**4.** Рус телендә язылган кулланманың булмавы, IMEI номерлар туры килмәве кешедә шик уятырга тиеш.

**5.** Сатучы телефон алу чегын, гарантия вакыты күрсәтелгән белешмәне, телефонның комплектына кергән өстәмә җиһазларны бирергә бурычлы. Документларда сатучының имзасы куелганмы, мөһер сугылганмы икәнен тикшерегез. Гарантия талоны дөрес тутырылган булырга тиеш. Товарның гарантия вакыты чыкканчы чекларын, документларны сакларга киңәш ителә.

## КУЛЛАНУЧЫЛАР ХОКУКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ СОРАУЛАР ТУГАНДА, БУШЛАЙ ЯРДӘМ ХЕЗМӘТЕ:

**Татарстанның дәүләт алкоголь инспекциясе**

**www.gosalcogol.tatar.ru**
**www.tatzpp.ru**

| Территориаль орган | Телефон |
|---|---|
| Әлмәт | (8553) 33-67-02 |
| Арча | (84366) 3-28-93 |
| Яшел Үзән | (84371) 4-58-78 |
| Казан | (843) 277-94-96 |
| Чаллы | (8552) 71-43-03 |
| Түбән Кама | (8555) 36-63-76 |
| Чистай | (84342) 5-49-85 |

**Татарстанда Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте идарәсе**

**(843) 236-94-11**
кайнар линия

**www.vk.com/zpprpnrt**
Татарстандагы Роспотребнадзор идарәсенең «ВКонтакте» дагы онлайн консультациясе

**www.16.rospotrebnadzor.ru**

**Татарстанның эпидемиология һәм гигиена үзәгендә консультация үзәге**

**(843) 221-90-16** **www.fbuz16.ru**

**Игътибар! Хокукларыгыз бозылган очракта, Роспотребнадзорның Татарстан идарәсенә гариза бирә аласыз, шулай ук республиканың күп функцияле үзәкләрендә кулланучы хокукларына кагылышлы сорауларга скайп аша консультация алырга була.**

6+

© ООО «ФОЛИАНТ», 2020 г.
Тираж 10000 экз. Заказ №72/16
Отпечатано ООО «ФОЛИАНТ». 420111 г. Казань, ул. Профсоюзная, 17в
e-mail: foliantkazan@mail.ru



«Татарстан Республикасында 2014–2025 елларда кулланучылар хокукларын яклау системасын комплекслы үстерү» программасы кысаларында, «Шәһри Казан» Татарстанның иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни газетасы белән берлектә, Татарстан Дәүләт алкоголь инспекциясенең заказы буенча әзерләнде

# ТЕЛЕФОН САТЫП АЛГАНДА КУЛЛАНУЧЫЛАР ХОКУКЛАРЫ

**КУЛЛАНУЧЫЛАР ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ**

Телефон техник яктан катлаулы товар булып санала. Шуңа да аны күңелгә хуш килми дип кенә кибеткә кире илтеп биреп булмый, бары җитешсезлекләр ачыкланган очракта гына шикаять белдерергә мөмкин.

## СЫЙФАТСЫЗ ТОВАРНЫ НИЧЕК КАЙТАРЫРГА?

Россия Федерациясе «Кулланучылар хокукларын яклау турында»гы 2300-1 нче номерлы законның (1992 елның 7 февраленнән гамәлдә) 4 нче маддәсе, 3 нче пункты нигезендә, әгәр дә кулланучы сатучыга товарны нинди максатлар өчен сатып алырга теләвен ике арада килешү төзелгәнче аңлаткан икән, димәк, сатучы аңа нәкъ менә шундый товарны бирергә бурычлы. «Кулланучылар хокуклары турында»гы законның 18 нче маддәсе нигезендә, әгәр товарның кимчелекләре турында сатучы алдан кисәтмәгән булса, сатып алганнан соң 15 көн эчендә ул кимчелекләр ачыкланса, кулланучы телефонны шундый ук маркадагы башкасына алыштыра ала. Түләү шарты белән, кулланучыга башка төрле маркадагы телефон тәкъдим итә алалар. Кулланучы кимчелекләре булган телефонның бәясен төшерүне, телефонның җитешсезлекләрен төзәтүне яки үзе һәм башка берәү төзәткән өчен акчасын түләүне таләп итәргә дә хаклы. Шулай ук, сатып алу килешүеннән баш тартып, товар өчен акчаны кире алырга да була.

«Кулланучылар хокуклары турында»гы законның 19 нчы маддәсе буенча, гарантия вакыты чыкканчы, әгәр ул күрсәтелмәгән булса, телефонны сатып алганнан соң ике ел эчендә шикаять язарга була. Телефонның җитешсезлекләре буенча сатучы белән кулланучы арасында бәхәс килеп чыккан икән, закон нигезендә, сатучы гарантия вакыты чыкмаган очракта, үз хисабына телефонга экспертиза үткәрергә бурычлы. Кулланучының экспертизада катнашырга хокукы бар. Ул хәтта тикшерү нәтиҗәсе белән килешмәскә дә мөмкин. Үз хокукларын судта яклый ала.

Телефонның кимчелекләре сатып алганнан соң 15 көн эчендә ачыкланса, проблеманы хәл итүе җайлырак булачак, шуңа да телефонны алгач та, аны кулланырга, функцияләрен тикшерергә киңәш ителә. Ә 15 көн узгач җитешсезлекләр ачыкланса, бары телефон өчен бәяне киметүне, йә кимчелекләрне төзәтүне генә таләп итә аласыз. Дөрес, әгәр дә җитди җитешсезлек турында сүз барса, товарны төзәтергә алып калган очракта, вакытында кайтармасалар, гарантия гамәлдә булган вакытта телефонны гел төзәтеп торырга туры килсә, шикаять юлларга мөмкин.

## ТЕЛЕФОН ТӨШЕП ВАТЫЛСА?

Әгәр дә телефонны имииниятләштергәнсез икән, сервис үзәгенә барып, телефонның ватылу сәбәбен теркәргә кирәк. Сервиста хезмәткәрләр акт төзеячәк, техниканың ремонтка яраклымы, юкмы икәнен билгеләячәк. Бу акт белән кулланучы иминиятләштерү компаниясенә барырга хокуклы.

## ТЕЛЕФОНГА ӨСТӘМӘ ГАРАНТИЯ КИРӘКМЕ?

Гадәттә, телефонга һәрчак гарантия бирелә. «Кулланучылар хокукларын яклау турында»гы законның 5 нче маддәсенең 6 нчы пункты буенча, җитештерүче товарга гарантия вакытын билгели. Бу – кимчелек ачыкланса, җитештерүче, закон нигезендә, кулланучының таләпләрен канәгатьләндерергә мөмкин булган вакыт дигән сүз. Гарантия вакытын билгеләү – сатучының хокукы, бу мәҗбүри түгел. Әгәр дә товарның гарантия вакыты күрсәтелмәгән икән, кимчелекләр ачыкланган очракта, телефонны сатып алганнан соң ике ел эчендә шикаять белдерергә була. Законның 5 нче маддәсенең 1 нче пункты нигезендә, җитештерүченең товарны куллану вакытын билгеләргә дә хокукы бар. Монысы тиешле максатларда кулланган очракта, җитештерүче товары өчен җаваплы булган вакытны аңлата. Әгәр товарда куллану вакыты күрсәтелмәгән икән, товарны сатып алганнан соң 10 ел эчендә җитештерүчегә таләпләрегезне белдерә аласыз.

Сатучы өстәмә гарантия билгели ала. Әлеге гарантиянең вакыты сатучы белән кулланучы арасында сөйләшенә, килешенә. Өстәмә гарантия өчен түләгәнче, аның шартлары белән ныклап танышып чыгарга киңәш ителә.

## ӘГӘР ТЕЛЕФОННЫ УРЛАСАЛАР?

Бу очракта полициягә, кизү тору бүлегенә барырга кирәк. Барысын да аңлатып, гариза язарга туры киләчәк. Хокук саклаучылар